СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru.

**Арча муниципаль районы**
**Шушмабаш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 30 » март 2021 ел** **№ 23**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарны сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының 18.12.2020 ел, №15 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Шушмабаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру, шулай ук Шушмабаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан карарлар кабул иткәндә халык фикерен ачыклау һәм аны исәпкә алу максатыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарны сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының 18.12.2020 ел, №15 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарны сораштыру билгеләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә" түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге гражданнарын сораштыру түбәндәге инициатива белән үткәрелә:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге

Советы яисә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы инициативасы белән -җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча;

- Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы белән- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге җирләренең региональ һәм регионара әһәмияттәге объектлар өчен максатчан билгеләнешен үзгәртү мәсьәләләре буенча;

- инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган муниципаль берәмлектә яисә аның өлешендә уналты яшькә җиткән яшәүчеләр инициативасы белән - әлеге инициатив проектка ярдәм күрсәтү буенча гражданнарның фикерен ачыклау өчен.»;

1.2. 5.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советына караган сораштыру үткәрү инициативасы күрсәтелгән орган тарафыннан сораштыру билгеләү турында тиешле карар кабул итүдә чагыла.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башлыгына караган сораштыру уздыру инициативасы Җирлек Советына сораштыру үткәрү турында үтенечнамә юллауда чагыла.

Муниципаль берәмлек яисә аның өлеше халкына караган сораштыру үткәрү инициативасы инициатив төркем тарафыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советына сораштыру үткәрү турында үтенечнамә юллауда чагыла;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл
җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов